


СЕРГЕЙ МИХАЛКОВ

СТЕПАН АБЫЙ-МИЛИЦИОНЕР

Сергей Михалков

СТЕПАН АБЫЙ-МИЛИЦИОНЕР



Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1960



КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Михалков Сергей Владимирович

ДЯДЯ СТЁПА — МИЛИЦИОНЕР

(на татарском языке)

Редакторы *Х. Камалов*

Художник *Г. Мазурин* рәсемнәреннән күчермә

Художество редакторы *Х. Әхмәтҗанов*

Техник редакторы *Ә. Трофимова*

Корректоры *А. Зарипова*

Производствога бирелде 29|IV-60 ел. Басарга кул куелды 12|X-60 ел. Кәгазь форматы 70x92 1|16. Учетн.-изд. 0,63 табак. Басма табак 1,0(1,17). Тираж 30 000 экз. Заказ И-326. Бәясе 20 тиен 1961 елның 1 гыйнвареннан 02 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуп исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1960 ел.



Степан абыйны кем белми?
Якын ул безгә һаман!
Һәркем белә: Степан абый
Моряк иде бер заман.

Яши иде почмак йортта,
Ильич заставасында,
Каланча иде, беләбез
Аның кушаматын да.

Данлыклы пәһлеваннарның
Арасында бүген дә
Яши Степан Степанов,
Шатлык биреп күнелгә.

Ул район буенча йөри,
Алсу погоннар таккан,
Иңенә ул пистолетлы
Күн кобура да аскан.

Фуражкасында кокарда,
Сары каеш билендә,
Герблы прәшкәсенен
Нур уйный һәр җирендә.

Ул дежурга чыгып бара,
Шул чакта бер пионер
Шаккатып авызын ача:
„Менә ми-ли-ци-о-нер!"

Хөрмәтләп Степан абыйны
Олылар һәм балалар
Елмаешып, кызыксынып,
Мактап сөйләп калалар:

„Мондый озын абыйлар
Алай еш очрамыйлар!

Тырышка, булдыклыга
Килешә формасы да!
Басса мәйдан түренә,
Бер чакрымнан күренә!.."

Юл тыгылган, тоткарланган,
Машиналар тукталган;
Бер светофор ватылган:



Яшел уты — юк кына,
Яна сары ут кына...

Җыелган йөз машина,
Һәммәсе дә ашыга.
Өч, дүрт, биш минут үтә,
Алар яшел ут көтә.

Шул чагында Степан абый
Әйтә хезмәттәшенә:
— Начармы эшең, туганкай?
Утларын янмый менә!

Пыяла будка эченнән
Җавап ала үзенә:
— Степанов, шаяртма әле!
Нишлик икән тиз генә?

Степан сүз көрәштерми —
Светофор эчен карый,
Аңа кулларын суза да
Нәрсәнедер боргалый...

Күз ачып күз йомганчы ук
Яшел ут янып китә,
Башлана тагын хәрәкәт,
Тоткарлык шундук бетә.





Шул чактан аны Мәскәүдә
Бик олылап сөйлиләр;
Ә нәниләр: — Степан абый—
Светофор, — дип йөриләр.

Нәрсә булган?
Зур вокзалда
Үксеп елый бер нәни;
Әнисен югалткан залда:
— Кайда, ди, минем әни?!

Һәркем милиция көтә,
Ул шунда ук килеп житә.
Елаганда нәни бала,
Степан абый аны ала;

Һәм, аркасыннан сөеп,
Башы түшәмгә тиеп
Торырлык итеп биек
Күтәрә дә шул чакта:
— Кара, ди, тирә-якка!

Аптек кибете янында,
Караса күзен йөртеп,
Баласын югалткан ана
Тора күз яшен сөртеп.

„Әни! Әни! Мин менә!“ —
Ана шатланып килә.
Степан абый бик канәгать:
„Бәхетле булды гаилә!“

Шук малайны һәркем бе-
лә, —
Ул мәктәптән кайтып килә.
Бәйләнергә жай эзли,
Каян башларга белми.

Каешта юк прәшкәсе,
Эмблемсыз фуражкасы,
Ә букчасында менә —
„Ике“ билгесе генә.



Әнә сөйләшеп үзара,
Ике дус кыз кайтып бара;
Ак алъяпкычтан үзләре,
Сокланырлык шат йөзләре,
Көндәлектә билгеләре —
Шәп укуның көзгеләре.

Көтмәгәндә бу шук малай
Кызлар каршына чыга,

Толымнарын тотып ала,
Төртеп пычракка ега.



Кызчыкларны эткәч-төрткәч,
Һич тә юкка җәбер иткәч,
Трамвай барганын күреп,
Ябыша да сикереп,
Тагын шуклыгын итә,
Бер аягын селкетә.

Белми ул Степан абыйның
Бик ерактан күргәнен,
Аның гафу итмәгәнен,
Бу шуклыгын белгәнен.

Универмаг ишегеннән
Шаян малайны саклап,
Степан абый мәйдан аша
Чыга өч кенә атлап.

Трамвай чаттан борылганда
Аны тотып төшерә:
„Син кем? Фамилиян ничек?
Кайда торасың? Сөйлә!“

Степан абый торып сакта,
Гаебеңне белгән чакта,
Булмый сүз көрәштереп,
Белгәнеңне яшереп.

Боз ярыла, боз китә:
Елга шарт та шырт итә.

Шул чак бозда, бәкедә
Әби кер чайкый менә.
Боз ярылып шарт итә,
Әби ага да китә.

Ул елый, ыңгыраша:
— Әй! Минем керем бата!
Әй, тизерәк алыгыз,
Әй, мине коткарыгыз!

Степан абый постында,
Күпернең уртасында.

Капитан күк шул чакта,
Караш ташлап еракка,
Күрә бозны, кәрзинне,
Агып барган әбине.

Монда нәрсә булганын,
Язып та булмый барын!
Карап елга бозларын,
Степан абый кулларын
Сузып аска бөгелә,
Рәшәткәдән түбәнгә,
Әбекәйгә үрелә.

Куркып елаган чакта
Аны ала кочакка.

Әби тота кәрзинен:
— Керем калмасын минем!

Коткара ул әбине,
Керләрне һәм кәрзинне.

Восстание мәйданыннан,
Бик биек йорт яныннан
Үткән чакта балалар
Аны күреп алалар.
Постта тора Степан,
Алар сөйгән пәһлеван.

Гаҗәпләнеп һәр бала
Янында туктап кала.



Сорау бирәләр шунда:
— Абый, сез ничек монда?
Сезнең бүлек еракта,
Бездән икенче якта!

Степан абый честь бирде,
Елмаеп болай диде:
— Мактаулы постка бастым мин
Һәм хәзер сезнен якта,
Биек йортыгыз янында,
Биек кешегез сакта!

Шоп-шома боз мәйданы,
Гөр килә тирә-ягы.
Китә ярыш башланып,
Торып баса бар халык.

Конькичылар шуалар,
Берсен-берсе куалар;
Тамашачы үзара
Сөйләшә: „Кара, кара,
Озын иң алда бара,
„8“ ле алда бара!“

Бер абзый, җитди генә,
Улыннан сорый менә:
— Бу бик озын аяклы
Кайсы команда яклы?
— Ай-яй, китерә жаен,
„Спартак“тан, мөгаен!

Әнисе әйтә шуннан:
— Бу коньки „Динамо“дан!
Кызганыч, шугалакта
„Спартак“ бара артта.

Судья абый хәбәр итә:
— Шуның белән ярыш бетә.
Степан абыйны котлап,
Һәркем мактый алкышлап.

Аның белән горурлана
Башкалада милиция.
Ул елмаеп карап ала,
Зур бүләк аңа тия!

Безнең абыйга — дуска
Барырга кирәк постка,
Аны юл уңаеннан,
Кем илтер икән моннан?

Шул вакытта яшь кенә
Шофер болай ди менә:

— Әйтәм, сезгә сокланып,
Илтер идем шатланып,
Кызганычка каршы сез
„Москвич“ка сыймыйсыз!

— Әй, Степанов, — ди бер шофер, —
Утыр, очабыз алга!

Кер тизрәк минем янга,
Атаклы самосвалга!

„Детский мир“ кибетендә,
Уенчык саткан жирдә,
Күрәләр хулиганны.
Ул чаналарны аударып,
Кесәсеннән кадак алып,
Тишә бер барабанны.

Әйтә сатучы: — Түлә, — ди,
Теге әйтә: — Түләмим!
— Милициягә илтикме?
— Үзем милиция мин!

Күзге аша Степанны
Күреп алгач артында,
Хулиган малай калтырап
Төшә баскан урнында.

— Бүлеккә алып китимме?
— Һич теләмим! Ник телим?
— Акчагызны түлисезме?
— Күпме торса да түлим!

Хулиганнарны күрсә,
Акылга ул тиз кертә.

Бер якшәмбе көнне иртән
Степан урамга чыга,

Һәм туктарга мәжбүр була,
Ябышкач бала-чага.

Витя начальникка карап,
Борнын жыерып ала:
— Гафу ит! Степан абый!
— Ни бар?
— Сорау! — ди бала.

— Флоттан соң ник кердегез
Милиция эшенә?
Башка эш табылмадымы
Шундый озын кешегә?

Степан абый каш жыера,
Сул күзен бераз кыса:
— Ярый, җавап бирәм, дуслар,
Шундый зур сорау туса!

Кызыксагыз бар хикмәтен
Һәм серен ачып салам:
Милиция хезмәтен мин
Бик тә кирәкле табам!

Пистолет белән яңгырда,
Эсседә, салкын чакта,
Чик сакчысы кебек ул да
Бик сизгер тора сакта.

Милиция әләктереп
Халыкка фаш итәр дип,

Вөжданы саф булмаганнар
Юкка шүрләмиләр бит!


Кайчак болай да була,
Елый көйсез бер бала, —
Юата ата-ана:
— Әнә милиция үтә,
Гел еласаң алып китә! —
Дип ул аны куркыта.

Моңарга кызарасың,
Бик гаҗәпкә каласың.
Болай әйтү юләрлек.
Ә безнең өчен гарьлек!



Әнә шулай яшь балалар,
Икенче классстагылар,
Степан абый янында
Аңлаштылар барын да.

Шау килеп озатты аны
Әйтерсең бер яңа хор:
— Сау бул! Сау бул! Сау бул, абый!
Степан абый — светофор!



Бәясе 20 тиен.
1961 елның 1 январеннан — 02 тиен.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1960